| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Кучуковского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Көчек авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

12.10.2023 Түбән Көчек авылы № 33-1

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Көчек авыл җирлеге Советының 20.11.2017 елның 29-2 номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәреш кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 394 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлеге Советы к а р а р ч ы г а р д ы:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Көчек авыл җирлеге Советының 20.11.2017 елның 29-2 номерлы «Җир салымы турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1 - 2 пунктның 8 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-башка җир кишәрлекләренә карата 1,5 %.».

1.2: 2 пунктның 3 абзацында «һәм объектларга» сүзләрен «һәм (яисә) объектларга» сүзләренә алмаштырырга, «объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлешләр» сүзләрен «күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлеге өлеше» сүзләренә алмаштырырга, «һәм объектларга» сүзләрен «һәм (яисә) объектларга» сүзләренә алмаштырырга

2. Әлеге карар 01.01.2024 елдан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлегенең мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы
вазифаларын вакытлыча башкаручы Р.Х.Баһаутдинов

Совет Кучуковского сельского поселения Көчек авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002526